**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4088**
**09.08.2019**

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын үткәрү турында

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлеген популярлаштыру максатында һәм Башкарма комитетның 2016 елның 27 октябрендәге 5659 нчы карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә 2019 елның 15 августыннан 30 ноябренә кадәр «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

1. Расларга:

1) конкурс турында нигезнамне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурска әзерлек һәм аны үткәрү чыгымнарын финанслауны 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты бүлегендә («Гомумдәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01 13 бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 250 000 (ике йөз илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 9 августындагы
4088 нче карарына
1 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренең
иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсы турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезнамә «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора.

3. Конкурсны үткәрү максаты – Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалары (алга таба – СЮ КБО) эшчәнлегенең ачыклыгын һәм аны популярлаштыруны тәэмин итү.

4. Конкурсның бурычлары:

1) граждан җәмгыяте үсешендә СЮ КБО эшчәнлеген популярлаштыру һәм ролен арттыру;

2) муниципаль берәмлекнең иҗтимагый киңлегендә СЮ КБОның уңай имиджын формалаштыру.;

3) СЮ КБО эшчәнлегенең ачыклыгын арттыру;

4) халыкның СЮ КБОларга ышанычын арттыру өчен шартлар тудыру;

5) халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүче иң яхшы СЮ КБОны ачыклау.

5. Конкурста катнашуга Яр Чаллы шәһәре территориясендә 1 елдан да ким булмаган эшчәнлек гамәлгә ашыручы СЮ КБОлар кертелә.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

6. Конкурс 2019 елның 15 августыннан 30 ноябренә кадәр 3 этапта үткәрелә:

1) 2019 елның 15 августыннан 15 сентябренә кадәр беренче этап: конкурста катнашучылар тарафыннан заявкалар һәм материаллар тапшыру;

2) 2019 елның 1 октябреннән 31 октябренә кадәр икенче этап: конкурс комиссиясе утырышы һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү;

3) 2019 елның ноябрендә өченче этап: җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы.

7. Конкурста катнашу өчен СЮ КБО вәкилләре 2019 елның 15 сентябренә кадәр «СЮ КБО КОНКУРСЫНА» тамгасы белән konkurs.sonko@yandex.ru электрон адресы буенча һәм вәкаләтле зат имзасы куелган һәм оешма мөһере сугылган кәгазь вариантагы заявканы Х. Туфан проспекты, 23 нче йорт, 106 кабинет (элемтә өчен телефон: 8(903)319-04-75, 8(951)898-12-07) адресы буенча Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә бирәләр.

8. Конкурста катнашу өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) форма буенча заявка (әлеге нигезнамәгә 1 нче кушымта);

2) СЮ КБО эшчәнлеге тасвирламасы (әлеге нигезнамәгә 2 нче кушымта);

3) гамәлгә кую документларының күчермәләре (устав, ОГРН таныклыгы, ИНН);

4) җитәкченең вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсе;

5) 2017-2019 еллар өчен СЮ КБО эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

6) СЮ КБО эшчәнлеге турында мәгълүмати материаллар (буклетлар, мәгълүмат битләре);

7) бүләкләү акчаларын күчерү өчен банк реквизитлары.

9. Конкурс үткәрү чорында мәгълүмати ачыклыкны тәэмин итү өчен документларны рәсмиләштерү буенча мәгълүмати-укыту семинары үткәрелә.

10. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Яр Чаллы шәһәре территориясендә тормышка ашырыла торган иң яхшы социаль әһәмиятле проект»;

2) «СЮ КБОның максатчан аудитория белән эшләүнең иң яхшы технологиясе»;

3) «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә СЮ КБО тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең иң яхшы тәҗрибәсе».

## 3 бүлек. Конкурс комиссиясе

11. «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба - комиссия) конкурс чараларын әзерләү һәм үткәрүне оештыру максатларында төзелә.

12. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

13. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурска тапшырылган документларны һәм материалларны карап тикшерә;

2) конкурста катнашучыларның казанышларын һәм проектларын, нәтиҗәләрен таратуда ярдәм күрсәтә;

3) конкурста җиңүчеләрне билгели.

14. Конкурс эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) хәл итүгә СЮ КБО эшчәнлеге юнәлдерелгән проблемаларның актуальлеге;

2) ярдәмнән файдаланучылар саны, аларның тормышындагы уңай үзгәрешләр;

3) проектларның әһәмияте һәм актуальлеге;

4) үткәрелгән чаралар саны;

5) максатчан төркем торышын яхшыртуга проект чараларының йогынты дәрәҗәсе;

6) СЮ КБО эшчәнлегенең дәвамлылыгы;

7) СЮ КБОның максатчан кертемнәрдән файдалану тәҗрибәсе булу.

15. Конкурста катнашучылар комиссия утырышында катнаша алмый.

16. Комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган составы катнашканда, комиссия утырышлары тулы хокуклы була. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларның гади күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия әгъзаларының утырышта һәм (яки) тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, аларның фикере язмача сораштыру ысулы белән исәпкә алынырга мөмкин.

17. Тавыш биргәнче, комиссия әгъзаларының барысы да конкурста катнашучыларның документлары һәм материаллары белән танышырга тиеш.

18. Комиссия җитәкчелеге комиссия рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла, ул комиссия эшен планлаштыра, комиссия утырышларын билгели һәм алып бара. Комиссия рәисе булмаган чорда утырышларны аның урынбасары үткәрә.

19. Комиссия секретаре комиссия утырышларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру һәм техник эшне гамәлгә ашыра, шул исәптән комиссия каравына тапшырыла торган документларны (мәгълүматларны) тикшерә, шулай ук комиссия карарларын рәсмиләштерә.

20. Комиссия карарлары, комиссия утырышы үткәрелгәннән соң өч көн эчендә комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм рәислек итүче тарафыннан раслана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

4 бүлек. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү

21. Һәр номинациядә өч җиңүче билгеләнә: беренче, икенче, өченче урыннар.

Һәр номинациядә җиңүчеләр беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге дипломнар, шулай ук түбәндәге бүләкләрне ала:

1) «Яр Чаллы шәһәре территориясендә тормышка ашырыла торган иң яхшы социаль әһәмиятле проект» номинациясе буенча: 1 урын – илле мең сум; 2 урын – утыз мең сум; 3 урын – ун мең сум;

2) «СЮ КБОның максатчан аудитория белән эшләүнең иң яхшы технологиясе» номинациясе буенча: 1 урын – кырык мең сум; 2 урын – утыз мең сум; 3 урын – ун мең сум;

3) «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә СЮ КБО тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең иң яхшы тәҗрибәсе» номинациясе буенча: 1 урын – кырык мең сум; 2 урын – утыз мең сум; 3 урын – ун мең сум.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсы турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

Заявка вәкаләтле зат имзасы белән фирма бланкында электрон төрдә һәм кәгазьдә тапшырыла.

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсында катнашуга
заявка

| | |
|---|---|
| СЮ КБО исеме | |
| «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ санлы Федераль законның 13.1 маддәсе нигезендә дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| СЮ КБО җитәкчесе | |
| СЮ КБО җитәкчесенең элемтә мәгълүматлары (электрон почта, телефоннар) | |

Җитәкче ________________/______________

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсы турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы
эшчәнлеге тасвирламасы
(3 ел өчен)

Барлык бүлекчәләр электрон рәвештә тутырыла. Әлеге бүлекнең күләме 6 биттән артырга тиеш түгел. Материалларны раслый торган норматив документлар, фото видео материаллар һ. б. белән тулыландырырга киңәш ителә. Кушымталарның гомуми күләме 25 биткә кадәр. Документлар вәкаләтле зат имзасы белән, электрон төрдә һәм кәгазьдә тапшырыла.

1. «Яр Чаллы шәһәре территориясендә тормышка ашырыла торган иң яхшы социаль әһәмиятле проект» номинациясе

| |
|---|
| Сезнең оешманың төп проектлары (аларны санагыз) |
| 2. Форма буенча төп проектлар турында сөйләгез: |
| 1. Проектның исеме |
| 2. Проектның максаты |
| 3.  Максатчан аудитория |
| 4. Актуальлек |
| 5. Сроклары |
| 7. Финанслау чыганаклары (корпоратив инвестицияләр, грантлар, шәхси иганәләр) |
| 8. Төп нәтиҗәләр (казанышлар), авырлыклар |
| 9. Проект партнерлары |

2. «СЮ КБОның максатчан аудитория белән эшләүнең иң яхшы технологиясе» номинациясе

| |
|---|
| 1. Максатчан аудитория |
| 2. Максатчан төркемнәр |
| 3. Соңгы 3 ел эчендә максатчан аудиториянең сан ягыннан составы |
| 4. Максатчан аудиториянең әлеге категориясенә тагын нинди оешмалар хезмәт күрсәтә? |
| 5. Сезнең өстенлек нәрсәдә? |
| 6. Һәр максатчан төркем өчен хезмәт күрсәтү формасы |
| 7. Соңгы 3 елда максатчан аудитория белән эшләү нәтиҗәләре |
| 8. Максатчан төркемне исәпкә алуның нинди формаларын алып барасыз? |

| |
|---|
| 9. Максатчан аудитория белән эшләү буенча нинди беренчел исәп документларын алып барасыз? |

3. «Яр Чаллы шәһәре халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә СЮ КБО тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең иң яхшы тәҗрибәсе» номинациясе

| |
|---|
| 1. Социаль хезмәтнең эчтәлеге |
| 2. Социаль хезмәтнең хокукый нигезе |
| 3. Социаль хезмәт күрсәтү өчен материаль-техник база (бүлмәләр, җиһазлар) нидән гыйбарәт? Профессиональ кадрларның (теләк белдерүчеләрнең) булуы. Социаль хезмәтнең мәгълүмати-методик эчтәлеге |
| 4. Социаль хезмәт күрсәтү формасы (эчтәлеге) |
| 5. Хезмәт эчтәлеген ача торган эчке документ бармы? |
| 6. Күрсәтелә торган социаль хезмәтнең сыйфатын мониторинглау механизмы (нәтиҗәлелек критерийлары) нинди? |
| 7. Күрсәтелә торган хезмәт сыйфатын күтәрүнең башка ысуллары |
| 8. Күрсәтелә торган социаль хезмәт буенча беренчел исәпкә алу документлары бармы? |
| 9. 3 ел эчендә социаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә ирешелгән (сез горурлана торган) нәтиҗәләр. |
| 10. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә перспектив юнәлешләр |

Башкарма комитетның
2019 елның 9 августындагы
4088 нче карарына
2 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын үткәрү буенча
конкурс комиссиясе
составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Гыйлаҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | комиссия рәисе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| 2. | Байдакова Надежда Фердәвис кызы | рәис урынбасары, «Игелекле йөрәкләр берлеге» АКБО җитәкчесе (килешенү буенча) |
| 3. | Дремуха Янина Вячеславовна | комиссия секретаре, социаль эшмәкәрләр ассоциациясе җитәкчесе (килешенү буенча) |
| | комиссия әгъзалары: | |
| 4. | Батюшов Абдулхак Мостафа улы | Шәһәр Советы депутаты, мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссия рәисе (килешенү буенча) |
| 5. | Садриева Альфира Мәхмүд кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, социаль планлаштыру бүлеге башлыгы |
| 6. | Зайцева Валентина Алексеевна | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет Рәисе (килешенү буенча) |
| 7. | Камалетдинова Ләлә Әнвәр кызы | Шәһәр Советы депутаты, гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе (килешенү буенча) |
| 8. | Сәхәбиева Рәзилә Рәхимҗан кызы | «Чиста бит» экологик хәрәкәте җитәкчесе (килешенү буенча) |
| 9. | Комадорова Ирина Владимировна | «Юниор парк» балаларны үстерү үзәге» АКБО җитәкчесе (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 9 августындагы
4088 нче карарына
3 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле
коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын үткәрүгә
смета

| Т/с | Чыгымнар исеме | Сумма |
|---|---|---|
| 1. | Призлар фонды | 250 000 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова